**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 апрель № 244

г. Казань

«Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\244.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 22 апрель, 244 нче
карары белән расланды

**«Кванториум» балалар технопаркы»
автоном коммерциячел булмаган оешмасына субсидия бирү
тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм «Кванториум» балалар технопаркы» автоном коммерциячел булмаган оешмасына (алга таба – Кванториум) субсидия бирү механизмын билгели.

2. Субсидия Кванториумның уставында күздә тотылган эшчәнлек төрләрен тормышка ашыруга чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында бирелә.

3. Субсидия бирү Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына (алга таба – Вәкаләтле орган) билгеләнгән тәртиптә әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Субсидия алу өчен Кванториум Вәкаләтле органга түбәндәге документларны кертә:

Вәкаләтле орган раслаган форма буенча субсидия алуга заявка;

билгеләнгән тәртиптә таныкланган:

Кванториумны гамәлгә кую документлары күчермәләре;

Кванториумның уставында күздә тотылган эшчәнлек төрләрен тормышка ашыруга чыгымнар сметасы.

5. Субсидия бирү Вәкаләтле орган һәм Кванториум арасындагы субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү Вәкаләтле орган раслаган форма буенча әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документларны Вәкаләтле органга керткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә төзелә.

Килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, субсидия бирү шартлары, аннан файдалану турындагы хисап кертү тәртибе һәм вакытлары, агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен кире кайтару очраклары, Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыруга Кванториумның ризалыгы, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очраклардан тыш, алынган акча исәбеннән чит ил валютасы алуны тыю күздә тотыла.

6. Вәкаләтле орган субсидияне Килешүдә билгеләнгән вакытта Кванториумның кредит оешмасында ачылган хисап счетына күчерә.

7. Кванториум субсидиянең күчерелүе һәм файдаланылуы буенча аерым бухгалтерлык исәп-хисабы алып бара.

8. Кванториум Вәкаләтле органга Килешүдә күздә тотылган форма һәм тәртип нигезендә субсидиядән файдалану турында хисап кертә.

9. Субсидия Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Кванториум тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар керткән очракта – тулы күләмдә;

субсидиядән файдалану турында хисап кертмәгән очракта – тулы күләмдә;

субсидия акчасыннан максатка ярашсыз файдалану ачыкланган очракта – субсидиядән максатка ярашсыз файдаланган күләмдә.

10. Килешүдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә Кванториум тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

11. Кванториум әлеге Тәртипнең 9 нчы һәм 10 нчы пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытларын бозган очракта, Вәкаләтле орган субсидияне кайтару вакыты чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча законнар белән билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

12. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Кванториумның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

13. Субсидиядән максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Вәкаләтле орган тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

---